37. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 30.9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 145407-6 номерлы федераль закон проекты турында (административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә төзелгән коллегиаль органнар тарафыннан чыгарылган карарларга шикаять бирү тәртибен төгәлләштерү өлешендә).

38. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 153856-6 номерлы федераль закон проекты турында (Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.13 статьясында каралган административ хокук бозулар турында эшләр кузгату өчен нигезләрне төгәлләштерү өлешендә).

39. «РСФСР кайбер закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) һәм «РСФСР Конституция Суды турында» РСФСР Законына, «РСФСР дәүләт салым хезмәте турында» РСФСР Законына һәм РСФСР Югары Советы Президиумының 1967 елның 3 июнендәге Указы белән расланган Балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссияләр турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Россия Федерациясе Законының үз көчләрен югалтуын тану турында» 172121-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

40. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 173930-6 номерлы федераль закон проекты хакында (кулланучылар хокукларын бозган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү өлешендә).

41. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2585-IV ДС

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1890. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларын раслау турында

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 159 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары итеп түбәндәге затларны расларга:

Атласов Николай Михайлович – «Проминдустрия» ҖЧҖ гамәлгә куючысы, финанс директоры

Ахунҗанов Хәлим Юлдаш улы – «Бөтенроссия электропрофсоюз» иҗтимагый берләшмәсенең Татарстан Республикасы Электропрофсоюзы рәисе

Бикчәнтәева Ләлә Дмитриевна – «Яшьләр казанышы» Казан үзәге иҗтимагый оешмасының башкарма директоры

Вавилов Владимир Владимирович – Лейкемия белән авыручы балаларга ярдәм итүнең Анжела Вавилова исемендәге Татарстан Республикасы иҗтимагый хәйрия фонды рәисе

Габдрахманов Фәнил Исхак улы – «Хезмәтне саклауның региональара ассоциациясе» коммерциячел булмаган оешмасы рәисе

Гайфуллина Миләүшә Хафиз кызы – Республика клиник тире-венерология диспансерының физиотерапия бүлеге мөдире

Гыйльмиева Римма Хәмид кызы – Россия мәгариф академиясенең Һөнәр белеменең педагогика һәм психология институтының педагогик белем һәм гуманитар әзерлек лабораториясе мөдире, «Социаль белем академиясе» БҖБ ХМУ җәмәгатьчелек белән багланышлар буенча проректоры

Гыймадетдинов Айрат Фердинанд улы – «АУДЭКС» ЯАҖ генераль директоры

Забегина Татьяна Вениаминовна – «Эбиволь» ЯАҖ директоры

Җәбирова Фәридә Мөхәммәт кызы – Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының шәһәр төзелеше кафедрасы өлкән мөгаллиме, «Җәбир» ҖЧҖ директоры, Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының дәүләт тарихи-мәдәни экспертиза уздыру буенча аттестацияләнгән эксперты

Җәләлов Рәфыйк Гали улы – Россия Пенсия фондының Буа районындагы һәм Буа шәһәрендәге идарәсе башлыгы

Застела Михаил Юрьевич – КФТТУ-КАИ профессоры, «Пионер» ТМШ рәистәше

Крамин Тимур Владимирович – Икътисад, идарә һәм хокук институты каршындагы социаль-икътисадый проблемаларның фәнни-тикшеренү институты директоры

Лихачева Ильнара Васильевна – «Хотня трейдинг» ҖЧҖ коммерция директоры

Маруденко Сергей Павлович – «ЭПЗВКНИИВОЛТ» ҖЧҖ генераль директоры

Наумов Артем Юрьевич – «ОПОРА РОССИИ» кече һәм урта эшкуарлыкның гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан региональ бүлекчәсенең башкарма директоры, «Вовремя.ру» ҖЧҖ эшлекле интернет басмасы директоры

Хәкимов Равиль Гыйният улы – Татарстан Республикасы Сугыш һәм хәрби хезмәт ветераннары (инвалидлары) иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары

Хуҗина Фәридә Йосыф кызы – «Татфондбанк» АИКБ ААҖ идарәсе рәисе ярдәмчесе

Юшканцева Татьяна Станиславовна – «Таттелеком» ААҖ генераль директорының персонал белән идарә итү буенча урынбасары

Яруллин Гомәр Кәрим улы – «Татарстан Республикасы «Татнефть» ААҖ һөнәр берлеге» иҗтимагый оешмасы рәисе.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2586-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1891. «2012 елга, 2013 һәм 2014 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 3445-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән «2012 елга, 2013 һәм 2014 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына

үзгәрешләр кертү хакында» 3445-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2587-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1892. «2012 елга, 2013 һәм 2014 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (3445-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «2012 елга, 2013 һәм 2014 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (3445-4 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Әлеге законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2588-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1893. «2012 елга, 2013 һәм 2014 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 3446-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән «2012 елга, 2013 һәм 2014 еллар план чорына Татарстан

Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 3446-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2589-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1894. «2012 елга, 2013 һәм 2014 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (3446-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «2012 елга, 2013 һәм 2014 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (3446-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Әлеге законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2590-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1895. «Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында» Татарстан Республикасы законы хакында (1434-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында» Татарстан Республикасы законын (1434-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2591-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1896. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (2377-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (2377-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Әлеге законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2592-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1897. «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (2422-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү

турында» Татарстан Республикасы законын (2422-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Әлеге законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2593-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1898. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль законның $16^6$ статьясын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы законы турында (4424-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль законның $16^6$ статьясын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы законын (4424-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Әлеге законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2594-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1899. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 1428-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 1428-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына әлеге закон проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына өченче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2595-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1900. «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистры турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 1438-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистры турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 1438-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2596-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1901. «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистры турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (1438-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистры турында» Татарстан Республикасы Законының 3

һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (1438-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2597-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1902. «Ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 4418-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 4418-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2598-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**1903. «Ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (4418-4 номерлы проект)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (4418-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Әлеге законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2599-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**1904. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 5437-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 5437-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2600-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1905. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (5437-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын (5437-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2601-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1906. «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 5433-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 5433-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2602-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1907. «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (5433-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (5433-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2603-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1908. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 5432-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 5432-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2604-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1909. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (5432-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын (5432-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Әлеге законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2605-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1910. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәреш кертү хакында» 6436-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәреш кертү хакында» 6436-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2606-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1911. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (6436-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (6436-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2607-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1912. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 30 һәм 38 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 7439-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 30 һәм 38 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 7439-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2608-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1913. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 30 һәм 38 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (7439-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 30 һәм 38 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (7439-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Әлеге законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2609-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1914. «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 1441-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары В.Н. Липужина һәм Н.Н. Рыбушкин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» Татарстан Республикасы

Законына үзгәрешләр кертү хакында» 1441-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2610-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1915. «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (1441-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (1441-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2611-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1916. «Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында» 7376-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Прокуроры тарафыннан кертелгән «Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында» 7376-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2612-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1917. «Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы законы турында (7376-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы законын (7376-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2613-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1918. «Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен куллану турында» 7440-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен куллану турында» 7440-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2614-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1919. «Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен куллану турында» Татарстан Республикасы законы хакында (7440-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен куллану турында» Татарстан Республикасы законын (7440-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2615-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1920. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 32 һәм 37 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 7431-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 32 һәм 37 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 7431-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертү вакытын 2013 елның 1 февраленә кадәр озайтырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2616-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1921. 2013 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. 2013 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планын расларга (оригиналга кушымта итеп бирелә).

2. Закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектлар 2013 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы нигезендә закон проектларын тиешле вакытта эшләүне һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертүне тәэмин итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2617-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1922. 2013 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының башка дәүләтләр, Россия Федерациясе субъектлары парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлеге планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. 2013 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының башка дәүләтләр, Россия Федерациясе субъектлары парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлеге планын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. 2013 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының башка дәүләтләр, Россия Федерациясе субъектлары парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлеге планы үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.А. Ратниковага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2618-IV ДС

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының
2012 елның 24 декабрендәге
2618-IV ДС номерлы
карары белән расланды

# 2013 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының башка дәүләтләр, Россия Федерациясе субъектлары парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлеге планы

| | Чара исеме | Үткәрү вакытлары | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| | **1. Башка дәүләтләрнең, Россия Федерациясе субъектларының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән хезмәттәшлек турында килешүләр төзегән парламентлары белән хезмәттәшлек** | | |
| 1.1. | Ике яклы парламент төркемнәренең хезмәттәшлеге турындагы килешүләрне һәм беркетмәләрне гамәлгә ашыру буенча уртак эшче комиссияләр төзү; хезмәттәшлек турындагы килешүләрне һәм беркетмәләрне гамәлгә ашыру кысаларында:<br>а) закон чыгару эшчәнлеге һәм контроль эшчәнлеге тәҗрибәсен алмашу (шул исәптән бюджет үтәлеше буенча);<br>б) закон актларын һәм эчке куллану документларын (парламентларның регламентлары, комитетлар һәм комиссияләр турындагы, аппарат турындагы һәм башка нигезләмәләр), шулай ук Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кергән закон чыгару инициативасы проектларын алмашу;<br>в) Россия Федерациясе субъектлары парламентларының утырышларында катнашу (визитлар кысаларында);<br>г) Россия Федерациясе субъектлары парламентларының комитетлары һәм комиссияләре арасында, шулай ук аппаратларының структур бүлекчәләре арасында контактлар;<br>д) Россия Федерациясе субъектлары парламентларында һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының дәүләт граждан хезмәткәрләре стажировкаларын оештыру; | ел дәвамында | а) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары<br><br>б) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары<br><br>г) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.2. | Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында һәм Федерация Советында закон чыгару эше буенча парламентара консультацияләр | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре |
| 1.3. | Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары чыгара торган һәм гамәлгә куючылары булган журналларны, газеталарны һәм башка басма продукцияне алмашу | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре |
| 1.4. | Россия Федерациясе субъектларына Татарстан Республикасының парламент делегацияләре визитларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру (рәсми чакырулар буенча) | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |
| | **2. Парламентара багланышларны киңәйтү** | | |
| 2.1. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында чит дәүләтләр делегацияләрен кабул итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |
| 2.2. | Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары, чит дәүләтләр парламентлары һәм чит дәүләтләрнең административ-территориаль берәмлекләре белән мәгълүмати һәм башка элемтәләр урнаштыру, тәҗрибә өйрәнү һәм хезмәттәшлекне үстерү. Хезмәттәшлек турында килешүләр һәм беркетмәләр төзү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2.3. | Россия Федерациясе Идел буе федераль округы субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары җитәкчеләре ассоциациясе эшендә катнашу | ел дәвамында (аерым график буенча) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе |
| | **3. Халыкара оешмалар белән хезмәттәшлек** | | |
| 3.1. | Европа Советының җирле һәм региональ хакимиятләре конгрессы эшендә катнашу | ел дәвамында (аерым график буенча) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе |
| 3.2. | Европа регионнары ассамблеясы эшендә катнашу | ел дәвамында (аерым график буенча) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе |
| | **4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларының парламентара хезмәттәшлеге** | | |
| 4.1. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларының Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы һәм Федерация Советының профильле комитетлары белән хезмәттәшлеге | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |
| 4.2. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларының түбәндәге комитетлар (комиссияләр) белән эшчәнлеге: | ел дәвамында | Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты |
| | а) Россия Федерациясе субъектлары парламентлары | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |
| | б) дәүләтчелекне һәм конституциячел-хокукый системаны үстерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе республикалары парламентлары | ел дәвамында | Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты |
| | в) Идел буе федераль округы составына керүче Россия Федерациясе субъектлары парламентлары | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | г) Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтае | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты, Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты, Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты |
| 4.3. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларының башка дәүләтләр парламентлары белән хезмәттәшлеге: | | |
| | Дәүләтчелекне һәм җирле үзидарәне үстерү мәсьәләләре буенча Бавария, Саксония һәм Тюрингия (Германия) федераль җирләр – бәйсез демократик дәүләтләр | ел дәвамында | Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты |
| 4.4. | «Толерантлык һәм миграцион процессларны глобализацияләү шартларында иминлек» темасына Россия-Канада конференциясен уздыру мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр әзерләү | март | Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты |
| | **5. Аналитик эш** | | |
| 5.1. | Муниципаль кадрлар сәясәте һәм муниципаль кадрлар резервын булдыру буенча Идел буе федераль округы составына керүче Россия Федерациясе субъектлары тәҗрибәсен өйрәнү | ел дәвамында | Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты |
| 5.2. | Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарының җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары белән үзара эшчәнлек тәҗрибәсен өйрәнү | ел дәвамында | Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5.3. | Түбәндәге мәсьәләләр буенча Россия Федерациясе субъектлары тәҗрибәсен өйрәнү:<br>– Россия Федерациясе республикаларын конституциячел-хокукый үстерү;<br>– закон чыгару эшчәнлеген аналитик тәэмин итүне камилләштерү;<br>– Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан законнарның торышы турындагы докладларны хокукый мониторинглау һәм әзерләү; | ел дәвамында | Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты |
| 5.4. | Мәгариф өлкәсендә законнарны камилләштерү буенча Россия Федерациясе субъектлары тәҗрибәсен өйрәнү | ел дәвамында | Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты |

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1923. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.19 һәм 9.11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.19 һәм 9.11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертергә.

2. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.19 һәм 9.11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

3. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, шулай ук Татарстан Республикасында сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.

4. Әлеге федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында карагандa Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми вәкиле итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Әбүбакиров Ришат Фазлетдин улын һәм Татарстан Республикасы юстиция министры Корманов Мидхәт Мәсхүт улын билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2619-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**1924. «Россия Федерациясе Граждан кодексының беренче, икенче, өченче һәм дүртенче өлешләренә, шулай ук Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 47538-6 номерлы федераль закон проекты хакында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Граждан кодексының беренче, икенче, өченче һәм дүртенче өлешләренә, шулай ук Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 47538-6 номерлы федераль закон проекты хакында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате текстын кабул итәргә.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының күрсәтелгән мөрәҗәгатен хуплауны сорап, Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару (вәкиллекле) органнарына мөрәҗәгать итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2620-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1925. Сәяси репрессияләрнең реабилитацияләнгән корбаннары хокукларын торгызу буенча республика комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2005 елның 26 маендагы 1292-III ДС номерлы карары белән төзелгән Сәяси репрессияләрнең реабилитацияләнгән корбаннары хокукларын торгызу буенча республика комиссиясе (алга таба – комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) комиссия составыннан Карузин Владимир Геннадьевичны, Терентьев Александр Михайловичны чыгарырга;

2) комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Беляков Роман Юрьевичны – Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасарын – Граждан җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлек итү идарәсе башлыгын;

комиссия рәисе урынбасары итеп раслап, Кадыйров Рөстәм Раиф улын –Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе башлыгын.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2621-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1926. Татарстан Республикасы Югары Ослан районы территориясендә торак пункт – Иннополис поселогын төзү турында

«Географик объектлар атамалары турында» 1997 елның 18 декабрендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы, «Татарстан Республикасының административ-территориаль корылышы турында» 2005 елның 7 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5, 10, 13, 19, 25 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан районы территориясендә торак пункт төзергә һәм аңа поселок статусы бирергә.

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советының яңа төзелгән торак пунктка «Иннополис» исемен бирү турындагы тәкъдиме белән килешергә.

3. Әлеге карарны күрсәтелгән поселокка исем бирүне нигезли торган материаллар һәм документлар белән Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенә экспертиза уздыру өчен җибәрергә.

4. Күрсәтелгән поселокка Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан исем бирелгәннән соң, аны Татарстан Республикасының исәпкә алу белешмәләренә кертергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2622-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1927. 45 нче Апас бермандатлы сайлау округы һәм 47 нче Кукмара бермандатлы сайлау округы буенча дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын өстәмә сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын тоту турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе хисабы һәм кандидатларның сайлау фондлары акчалары керү һәм аларны тоту турындагы белешмәләр хакында

45 нче Апас бермандатлы сайлау округы һәм 47 нче Кукмара бермандатлы сайлау округы буенча дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын өстәмә сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын тоту турында Та-

тарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе хисабын һәм кандидатларның сайлау фондлары акчалары керү һәм аларны тоту турындагы белешмәләр хакында тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

45 нче Апас бермандатлы сайлау округы һәм 47 нче Кукмара бермандатлы сайлау округы буенча дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын өстәмә сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын тоту турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе хисабын һәм кандидатларның сайлау фондлары акчалары керү һәм аларны тоту турындагы белешмәләрне игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2623-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1928. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетын сайлау турында» 2009 елның 19 мартындагы 15-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының унсигезенче абзацында «Шәрипова» сүзен «Паткина» сүзенә алмаштырырга.

2. «Профессиональ даими нигездә эшләү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау турында» 2009 елның 19 мартындагы 28-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының унберенче абзацында «Шәрипова» сүзен «Паткина» сүзенә алмаштырырга.

3. «Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, сәламәт яшәү рәвешен булдыру һәм Казан шәһәрендә уздырылачак 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиаданы әзерләүгә ярдәм итү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе төзү турында» 2009 елның 22 апрелендәге 81-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән расланган Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, сәламәт яшәү рәвешен булдыру һәм Ка-

зан шәһәрендә уздырылачак 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиаданы әзерләүгә ярдәм итү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составында унбишенче абзацта «Шәрипова» сүзен «Паткина» сүзенә алмаштырырга.

4. «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында» 2010 елның 23 сентябрендәге 1127-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының 1 пунктындагы 29 пунктчасының өченче абзацында «Шәрипова» сүзен «Паткина» сүзенә алмаштырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2624-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1929. «Фән һәм дәүләт фәнни-техник сәясәте турында» Федераль законның 16[1] статьясына үзгәреш кертү хакында» 156601-6 номерлы федераль закон проекты турында («инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәме» төшенчәсен төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Фән һәм дәүләт фәнни-техник сәясәте турында» Федераль законның 16[1] статьясына үзгәреш кертү хакында» 156601-6 номерлы федераль закон проектын («инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәме» төшенчәсен төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2625-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1930. Физик затларның – торак төзелешендә катнашучыларның мөлкәти хокукларын иминләштерү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Орел өлкә халык депутатлары Советы мөрәҗәгате турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Физик затларның – торак төзелешендә катнашучыларның мөлкәти хокукларын иминләштерү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Орел өлкә халык депутатлары Советы мөрәҗәгатен хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Орел өлкә халык депутатлары Советына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2626-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1931. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына урманнарда санитар иминлек һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозган өчен административ хокук бозулар составларын төгәлләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 168387-6 номерлы федераль закон проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына урманнарда санитар иминлек һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозган өчен административ хокук бозулар составларын төгәлләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 168387-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2627-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1932. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 168987-6 номерлы федераль закон проекты турында (мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендәге хокук бозулар өчен җаваплылыкны көчәйтү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 168987-6 номерлы федераль закон проектын (мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендәге хокук бозулар өчен җаваплылыкны көчәйтү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2628-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**1933. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 165168-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары карамагындагы һәм региональ әһәмияттәге махсус саклanyлучы табигать территорияләреннән файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге функцияләрен гамәлгә ашыручы дәүләт учреждениеләренең вазыйфаи затларына Кодексның 8.39 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү хокукы бирү хакында)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 165168-6 номерлы федераль закон проектын (Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары карамагындагы һәм региональ әһәмияттәге махсус саклanyлучы табигать территорияләреннән файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге функцияләрен гамәлгә ашыручы дәүләт учреждениеләренең вазыйфаи затларына Кодексның 8.39 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү хокукы бирү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2629-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1934. «Админисратив хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 165801-6 номерлы федераль закон проекты турында (торак йортлар подъездларында табигый хаҗәтләрен башкарган һәм шуның өчен билгеләнмәгән бүтән иҗтимагый урыннарда табигый хаҗәтләрен башкарган өчен административ җаваплылык билгеләү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Админисратив хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 165801-6 номерлы федераль закон проектын (торак йортлар подъездларында табигый хаҗәтләрен башкарган һәм шуның өчен билгеләнмәгән бүтән иҗтимагый урыннарда табигый хаҗәтләрен башкарган өчен административ җаваплылык билгеләү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2630-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1935. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының транспорт чаралары хәрәкәтенә һәм (яисә) тукталышына йә туктап торуына юл хәрәкәтендә катнашучы булмаган зат тарафыннан комачаулык тудырган өчен җаваплылык өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 173919-6 номерлы федераль закон проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының транспорт чаралары хәрәкәтенә һәм (яисә) тукталышына йә туктап торуына юл хәрәкәтендә катнашучы булмаган зат тарафыннан комачаулык тудырган өчен җаваплылык өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 173919-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 24 декабре
№ 2631-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1936. «Россия Федерациясендә эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле затлар турында» Федераль закон кабул итүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 185349-6 номерлы федераль закон проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 12 декабрь
№ ПУ-1062

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

**1990. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында**

Күпьеллык фәнни-педагогик эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексы өчен квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Казан дәүләт аграр университеты» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең «Тракторлар, автомобильләр һәм энергетик җайланмалар» кафедрасы доценты | Галиев Геннадий Гали улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 13 декабрь
№ ПУ-1063

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1991. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы куркынычсызлыгын тәэмин итү эшендәге казанышлары, югары һөнәри осталык, үз-үзләрен аямау һәм батырлык үрнәкләре күрсәтүләре өчен:

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәре | Хәмитов Динар Газиз улын |
| 78705 х/ч хәрби хезмәткәре | Щедрин Игорь Петровичны |

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 13 декабрь
№ ПУ-1065

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1992. «Татарстан Республикасының Атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм халыкка хезмәт күрсәтүнең сыйфатын күтәрүдәге өлеше өчен

| | |
|---|---|
| «Чаллы икмәге сәүдә йорты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең операцияләр директоры, Чаллы шәһәре | Домашнева Галина Васильевнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 14 декабрь
№ ПУ-1066

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1993. «Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Татарстан Республикасында спортның техник төрләрен үстерүдәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасының Автомобиль һәм мотоциклет спорты федерациясе» төбәк җәмәгать оешмасы президиумы әгъзасы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе башлыгы | Миңнеханов Рифкать Нургали улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 14 декабрь
№ ПУ-1067

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1994. «Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Татарстан Республикасында спортның техник төрләрен үстерүдәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасының Автомобиль һәм мотоциклет спорты федерациясе» төбәк җәмәгать оешмасы автоспортчысы | Тимерҗанов Тимур Ренат улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 14 декабрь
№ ПУ-1068

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1995. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм актив җәмәгать эшчәнлеге өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Югары Суды администраторы | Галиуллин Рафаэль Рәхмәтулла улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 14 декабрь
№ ПУ-1069

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1996. Татарстан Республикасының кайбер торак пунктларында һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Аксубай районының Иляшкино авылы;

Биектау районының Кече Бөреле авылы;

Кукмара районының Аш-Бузи авылы;

Спас районының «КИМ» совхозындагы 2 номерлы Ферма поселогы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Азнакай шәһәренең Садовая урамы;

Аксубай районының Иске Савруш авылындагы Комсомол урамы;

Әлки районының Базарлы Матак авылындагы Тукай урамы;

Апас районының Урта Биябаш авылындагы Гагарин урамы;

Кукмара районының Зур Сәрдек авылындагы Үзәк урамы;

Минзәлә районының Югары Тәкермән авылындагы 8 Март урамы;

Азнакай районы Зур Сукаеш авылының Мәктәп урамындагы 22-29 номерлы шәхси йорт хуҗалыклары;

Балтач районы Арбор авылының Татарстан урамындагы 92-100 номерлы шәхси йорт хуҗалыклары;

Балтач районы Янгул авылының Әшрәфҗанов урамындагы 1-11 номерлы шәхси йорт хуҗалыклары;

Алексеевск районы Зур Полянка авыл җирлегенең Зур Полянка авылыннан төньяк-көнбатыш юнәлештә 1500 метр ераклыкта урнашкан 2 гектар мәйдандагы җирләре;

Арча районы Сеҗе авыл җирлегенең Мөрәле авылыннан төньяк-көнбатыш юнәлештә 3000 метр ераклыкта урнашкан 2 гектар мәйдандагы җирләре.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару һәм кыргый җәнлекләрне (аларны зоопаркларга чыгару өчен, башка районнарда үрчетү максатларында) тоту;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудыра торган хайваннарны ит өчен сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аларның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 17 декабрь
№ ПУ-1073

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1997. С.Л. Батинны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы әгъзасы – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органыннан вәкил итеп билгеләп кую турында

«Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советын формалаштыру тәртибе турында» Федераль законның 4 һәм 5 статьялары нигезендә карар бирәм:

1. Сергей Леонидович Батинны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы әгъзасы – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органыннан вәкил итеп билгеләп куярга.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 19 декабрь
№ ПУ-1074

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1998. «Татарстан Республикасының Атказанган транспорт хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте, тимер юл транспорты эшчәнлеген үстерүгә һәм камилләштерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Хәрәкәт белән идарә итү үзәк дирекциясе структур бүлекчәсе – Хәрәкәт белән идарә итү Куйбышев дирекциясе структур бүлекчәсе – Түбән Кама тимер юл станцияләре эшен оештыру үзәгенең Писмән тимер юл станциясе буенча дежурные, Лениногорск шәһәре | Тушина Нина Кузьминичнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган транспорт хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 19 декабрь
№ ПУ-1075

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1999. Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының 3[1] статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Балтач районының Түбән Кенә авылы;

Биектау районының Татар Урматы авылы;

Кайбыч районының Надеждино авылы;

Кайбыч районының Кичкеево авылы;

Саба районының Пукәл авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Арча районының Кызыл Игенче авылындагы Дальняя урамы;

Арча районының Түбән Оры авылындагы Җиңү урамы;

Биектау районының Инеш поселогындагы Муса Җәлил урамы;

Сарман районының Мортыштамак авылындагы Комсомол урамы;

Казан шәһәренең Яңа Дәүләки урамы;

Казан шәһәренең Химическая урамындагы 7 номерлы йорт яны территориясе;

Чистай районының «Яуширмә» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Яуширмә авылы янындагы мөгезле эре терлек асрау өчен файдаланылучы «Азлан» җәйге лагере;

Балтач районындагы Кара күл яны территориясе.

2. Түбәндәгеләрнең үз көчләрен югалтуын танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Кайбыч районының Надеждино авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлегe сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 6 сентябрендәге ПУ-752 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлегe сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 8 октябрендәге ПУ-859 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлегe сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 9 октябрендәге ПУ-863 номерлы Указының 1 пунктындагы «а» пунктчасы, «б» пунктчасының икенче – алтынчы абзацлары;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлегe сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 13 октябрендәге ПУ-875 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 декабрь
№ ПУ-1076

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 2000. Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Азнакай районының Әгерҗе авылы;

Баулы районының Таллы Күл авылы;

Кайбыч районының Байморза авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Аксубай районының Түбән Татар Майнасы авылындагы Кече урам;

Баулы районының Шалты авылындагы Тукай урамы;

Бөгелмә районының Иске Сумароково авылындагы Нагорная урамы;

Югары Ослан районының Печищи авылындагы Грузин урамы;

Кукмара районының Югары Күзмис авылындагы Яшел урам;

Яңа Чишмә районының Черемухово Бистәсе авылындагы Совет урамы;

Тукай районының Сосновый Бор поселогындагы Дуслык урамы;

Балтач районы Мельничная авылының Колхоз урамындагы 1-10 номерлы шәхси йорт хуҗалыклары;

Әлки районының Приозерная авылы янындагы «Племенное Дело Алексеевское» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Приозерная» нәсел фермасы;

Бөгелмә районы Яңа Александровка авыл җирлегенең Иске Казанка авылыннан төньяк-көнбатыш юнәлештә 2000 метр ераклыкта урнашкан 1,5 гектар мәйдандагы җирләре.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару һәм кыргый җәнлекләрне (аларны зоопаркларга чыгару өчен, башка районнарда үрчетү максатларында) тоту;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудырган хайваннарны ит өчен сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 декабрь
№ ПУ-1077

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2001. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Президентының Тышкы элемтәләр департаменты төбәкара хезмәттәшлек һәм ватандашлар белән эшләү секторы баш киңәшчесе | Кормашева Светлана Марат кызын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 декабрь
№ ПУ-1078

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2002. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә башкарма органнарында күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары | Каширина Галина Михайловнаны |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 декабрь
№ ПУ-1079

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2003. «Татарстан Республикасының Атказанган энергетигы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм энергияне сак тоту өлкәсендәге казанышлары, һөнәри осталыгы өчен

| | |
|---|---|
| «Генерацияләүче компания» ачык акционер җәмгыятенең «Чаллы Җылылык – электр үзәге» филиалы җылылык цехының электр станцияләре җиһазларына хезмәт күрсәтү слесаре | Тубов Александр Павловичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган энергетигы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 декабрь
№ ПУ-1080

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2004. «Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасы халкы сәламәтлеген саклау эшендәге зур казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан күчерү станциясе» дәүләт автономияле сәламәтлек саклау учреждениесенең Әлмәт шәһәрендәге филиалы баш табибы | Таипов Таһир Әхсән улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 декабрь
№ ПУ-1081

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 2005. «Татарстан Республикасының Атказанган газ тармагы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Татарстан Республикасының газ хуҗалыгы системасында күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераннары:

Майоров Константин Федоровичка
Сәлимгәрәев Касыйм Сәлимгәрәй улына

«Татарстан Республикасының Атказанган газ тармагы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 декабрь
№ ПУ-1082

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 2006. «Татарстан Республикасының Атказанган газ тармагы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Татарстан Республикасының газ хуҗалыгы системасында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Газпром» ачык акционер җәмгыяте «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директорының җитештерү буенча урынбасары | Попов Алексей Гавриловичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган газ тармагы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 декабрь
№ ПУ-1083

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

**2007. «Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында**

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Әлмәт шәһәренең Волейбол федерациясе» иҗтимагый спорт оешмасы рәисе | Певцов Николай Егоровичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 декабрь
№ ПУ-1084

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

**2008. «Татарстан Республикасының Атказанган җиртөзәре» дигән мактаулы исем бирү турында**

Күпьеллык намуслы хезмәте, җиртөзәрлек һәм Татарстан Республикасының җир кадастры өлкәсендәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Кайбыч бүлеге башлыгы | Гобәева Лилия Шәфигулла кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган җиртөзәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 декабрь
№ ПУ-1085

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2009. «Татарстан Республикасының Атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә күпьеллык намуслы хезмәте, һөнәри эшчәнлектәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге башлыгы | Зайцева Тамара Владимировнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 декабрь
№ ПУ-1086

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2010. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте, югары һөнәри осталыгы, Татарстан Республикасында метрология хезмәтен үстерүгә зур өлеше өчен

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасында дәүләт стандартлаштыру, метрология һәм сынаулар төбәк үзәге» федераль бюджет учреждениесе директоры | Гогин Валерий Алексеевичны |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 21 декабрь
№ ПУ-1087

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2011. «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык намуслы хезмәтләре, Татарстан Республикасында җирле үзидарәне булдыруда һәм үстерүдәге казанышлары өчен:

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Иске Илтерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы | Альметкин Валерий Кимовичны |
| Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Дачный авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы | Ларин Евгений Александровичны |
| Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Маҗын авыл җирлеге Башкарма комитеты секретаре | Титова Нина Леонидовнаны |

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 21 декабрь
№ ПУ-1088

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2012. «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының эшчәнлеге эффективлыгын арттырудагы казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенең эшләр идарәсе финанс, смета-шартнамә бүлеге башлыгы | Кочнев Николай Васильевичны |

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 21 декабрь
№ ПУ-1089

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2013. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә классчы чиннар бирү турында

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә түбәндәге классчы чиннарны бирергә:

<u>Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы буенча</u>

**Татарстан Республикасының**
**2 классчы хакыйкый дәүләт киңәшчесе**

| | |
|---|---|
| министрның беренче урынбасары | Әюпова Ирада Хафизҗан кызына |

**Татарстан Республикасының**
**3 классчы хакыйкый дәүләт киңәшчесе**

| | |
|---|---|
| министр урынбасары | Нигъмәтуллина Гүзәл Азат кызына |
| министр урынбасары | Персова Светлана Глебовнага |

Татарстан Республикасы Хезмәт,
эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы буенча

**Татарстан Республикасының
1 класслы хакыйкый дәүләт киңәшчесе**

| | |
|---|---|
| министрның беренче урынбасары | Хәсәнов Айрат Радик улына |

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 21 декабрь
№ ПУ-1090

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2014. «Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте, халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автономияле сәламәтлек саклау учреждениесенең хирургия бүлекчәсе өлкән шәфкать туташы | Шәфиева Роза Алексеевнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 22 декабрь
№ ПУ-1091

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2015. «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, мәдәниятне саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Балалар сәнгать мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе директоры | Гайниева Рәмзия Ваккас кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 22 декабрь
№ ПУ-1092

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2016. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы, юриспруденция өлкәсе өчен кадрлар әзерләүдәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| «Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Россия хокук академиясе» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе Казан юридик институты (филиал) директоры | Петрунина Ирина Борисовнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 22 декабрь
№ ПУ-1093

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2017. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы прокуратурасының әйдәүче белгече | Зантимирова Сания Хәнифулла кызын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 22 декабрь
№ ПУ-1094

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2018. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте, плазма физикасы һәм астрофизика мәсьәләләрен өйрәнүгә зур өлеш кертүе, күпкырлы оештыру һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен

| | |
|---|---|
| Россия фәннәр академиясе һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы, физика-математика фәннәре докторы, Мэриленд университеты профессоры, «Көнчыгыш-Көнбатыш», АКШ фәнни тикшеренүләр үзәге җитәкчесе | Сәгъдиев Роальд Зиннур улын |

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 22 декабрь
№ ПУ-1095

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2019. «Татарстан Республикасының Атказанган җиртөзәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте, Татарстан Республикасының җиртөзәрлек һәм җир кадастры өлкәсендәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Тукай бүлеге башлыгы | Курочкина Елена Альбертовнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган җиртөзәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 22 декабрь
№ ПУ-1096

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2020. «Татарстан Республикасының Атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Эчке эшләр органнарында күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе, һөнәри осталыгы өчен

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе икътисадый куркынычсызлык һәм коррупциягә каршы көрәшү бүлеге башлыгы урынбасары – бүлекчә (агентура-оператив эш) башлыгы, полиция подполковнигы | Шейфер Андрей Егоровичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 22 декабрь
№ ПУ-1097

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2021. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен:

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Вахитов районы прокуроры урынбасары | Гавриленко Елена Николаевнага |
| Татарстан Республикасы Ютазы районы прокуроры | Гарифуллин Рамил Таһир улына |
| Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре прокурорының өлкән ярдәмчесе | Закирова Римма Галимҗан кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 22 декабрь
№ ПУ-1098

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2022. «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, Татарстан Республикасында җирле үзидарәне булдыруда һәм үстерүдәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Чәчәкле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы | Исмәгыйлева Әсхәдия Наил кызын |
| Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы | Нуриев Зөлфәт Равил улын |
| Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Яңа Тинчәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы | Тухфатуллов Мансур Шаһи улын |

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 22 декабрь
№ ПУ-1099

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

**2023. «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләү турында**

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Чистай муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе | Ситдыйков Әхмәт Әхәт улын |

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 22 декабрь
№ ПУ-1100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

**2024. «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләү турында**

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Сөләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы | Шайдуллина Гөлчәчәк Сәгыйдулла кызын |

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 22 декабрь
№ ПУ-1101

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2025. «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте, Татарстан Республикасында җирле үзидарәне булдыруда һәм үстерүдәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Иске Җөри авыл башкарма комитеты секретаре | Борһанова Фәүзия Фазыл кызын |

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 22 декабрь
№ ПУ-1102

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2026. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларын раслау турында

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары итеп расларга:

Батров Рөстәм Гаяр улын – Татарстан Республикасы Диния нәзарәтенең Голәмаләр шурасы рәисе, Россия Ислам институтының фәнни эш буенча проректорын;

Бахтиаров Тимур Александровичны – «Татарстан Республикасы иҗат яшьләре академиясе» җәмәгать оешмасы президентын;

Вәлиуллин Ренат Нәкыйф улын – «Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты» республика җәмәгать оешмасы рәисенең беренче урынбасарын;

Газиев Наил Хәмид улын – А.Н. Туполев исемендәге Казан милли-тикшеренү техник университетының гомуми химия һәм экология кафедрасы профессорын;

Зиннуров Ирек Хәйдәр улын – Балалар суда поло уены фондын үстерү президенты, «Синтез» ватерпол клубы баш тренеры;

Иштирәков Хәбир Газиз улын – Татарстан Республикасы Ветераннар (пенсионерлар) җәмәгать оешмасы Республика Советы рәисен;

Кириченко Светлана Владимировнаны – «АБАДА» идарә итү компетенцияләрен үстерү фәнни-тикшеренү үзәге Попечительләр советы президиумы рәисен;

Королев Валерий Васильевичны – Казан (Идел буе) федераль университеты философия факультетының дин белеме кафедрасы мөдирен;

Мезикова Илсөя Хамат кызын – Икътисад, идарә итү һәм хокук институтының (Казан шәһәре) Түбән Кама филиалы директорын;

Менделевич Владимир Давыдовичны – Казан дәүләт медицина университетының медицина һәм гомуми психология кафедрасы мөдирен;

Нуретдинов Гомәр Хәсәнҗан улын – Россия Федерациясе автомобиль һәм авыл хуҗалыгы машиналары төзү тармагы хезмәткәрләре һөнәри берлегенең «КАМАЗ» ачык акционер җәмгыяте хезмәткәрләре башлангыч профсоюз оешмасы рәисен;

протоиерей Иоаннны (Барсуков Иван Ивановичны) – настоятельне, Казан шәһәре Никольский кафедраль соборы приход советы рәисен;

Руденко Гөлзадә Рәкыйп кызын – Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы генераль директорын;

Смирнова Любовь Евгеньевнаны – Татарстан Республикасының Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Геройлары, Хәрби һәм Хезмәт Даны орденнары тулы кавалерлары «Татарстан Геройлары» җәмәгать хәйрия оешмасы рәисе урынбасарын;

Тимуца Ольга Вадимовнаны – «Ретта синдромы белән авыручылар ассоциациясе» автономияле коммерциячел булмаган оешмасы директорын;

Фомин Анатолий Алексеевичны – Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе киңәшчесен;

Халиков Тимур Рафаэль улын – «Идел буе аудиторлык үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте аудиторы ассистентын;

Хөснетдинова Гөлнар Равил кызын – Россия Федерациясе сәламәтлек саклау хезмәткәрләре һөнәри берлегенең Татарстан оешмасы рәисен;

Хухунашвили Маринэ Мануиловнаны – Казан шәһәренең «Күпмилләтле мәктәп» мәгариф үзәге директоры, Татарстан халыклары ассамблеясе Советы рәисе урынбасарын;

Яковлев Константин Геннадиевичны – «Мәгариф» төбәкара укыту-мәгълүмат үзәге генераль директоры, И.Н. Ульянов исемендәге Чуваш дәүләт университетының Казан шәһәрендәге вәкиллеге директорын.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 24 декабрь
№ ПУ-1103

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2027. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы, гражданнар хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклаудагы казанышлары өчен:

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Казан нотариаль округы нотариусы | Гыйльфанова Наталья Анатольевнага |
| Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының закон проектлары эшләү бүлеге башлыгы | Кәримова Әлфия Рәхимҗан кызына |
| Татарстан Республикасының Казан нотариаль округы нотариусы | Мальченкова Евгения Николаевнага |

| | |
|---|---|
| Этиль спирты, алкоголь продукциясе җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясе җитәкчесе | Марченко Игорь Александровичка |
| Татарстан Республикасы адвокатлар коллегиясенең Казан шәһәре Вахитов районы филиалы адвокаты | Ягъфәров Илдар Әнвәр улына |

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 24 декабрь
№ ПУ-1105

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2028. «Татарстан Республикасының Атказанган коткаручысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Авария, һәлакәтләр һәм табигать бәла-казаларын кисәтүдә һәм аларның нәтиҗәләрен бетерүдәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасы Граждан оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасы Эзләүкоткару хезмәте» дәүләт казна учреждениесенең 2 нче Казан зона эзләү-коткару отряды коткаручысы | Сухов Максим Валентиновичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган коткаручысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 24 декабрь
№ ПУ-1106

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 2029. «Татарстан Республикасының Атказанган транспорт хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте, һава транспортын үстерүгә һәм камилләштерүгә, пассажирларга хезмәт күрсәтүнең сыйфатын күтәрүгә, очышларның куркынычсызлыгын тәэмин итүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Тулпар Техник» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры, Казан шәһәре | Некрашевич Владимир Вячеславовичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган коткаручысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 24 декабрь
№ ПУ-1107

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 2030. «Татарстан Республикасының Атказанган транспорт хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте, Татарстан Республикасы территориясендә тимер юл транспортын үстерүгә һәм камилләштерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Тимер юлларны комплекслы реконструкцияләү һәм тимер юл транспорты объектлары төзү дирекциясенең төзү-монтаж эшләренең сыйфаты һәм аларны кабул итү инспекторы, Казан шәһәре | Азин Николай Ивановичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган транспорт хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 24 декабрь
№ ПУ-1108

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2031. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм Татарстан Республикасының юл төзелеше тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Татавтодор – Күпер төзү идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры, Казан шәһәре | Мостафаев Бәһрам Талыйб улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 24 декабрь
№ ПУ-1109

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2032. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының җитештерү һәм социаль әһәмиятле объектларын газлаштыру буенча инвестиция программаларын үтәүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Фоника Гипс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте Директорлар советы рәисе | Забарский Александр Абрамовичны |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 24 декабрь
№ ПУ-1110

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2033. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте, инновацияле производство булдыру һәм Татарстан Республикасы икътисадын үстерү эшенә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Пыяла-пластик торба заводы» фәнни-җитештерү предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры, Казан шәһәре | Волков Сергей Алексеевичны |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 24 декабрь
№ ПУ-1111

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2034. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, финанс-икътисад эшчәнлегендәге зур казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты төбәк бүлекчәсе җитәкчесе, Мамадыш муниципаль районы | Абрамова Нина Яковлевнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 24 декабрь
№ ПУ-1112

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2035. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, финанс-икътисад эшчәнлегендәге зур казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасы Милли банкы Программа комплексларын тәэмин итү идарәсе башлыгы урынбасары | Терентьева Наталья Юрьевнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 24 декабрь
№ ПУ-1113

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2036. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, финанс-икътисад эшчәнлегендәге зур казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| «Казан Үзәк универсаль кибете Сәүдә йорты» ачык акционер җәмгыятенең икътисадый анализ һәм автоматлаштырылган идарә системасы бүлеге башлыгы | Гыйлаҗева Гөлсинә Әмирсалих кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 24 декабрь
№ ПУ-1114

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2037. «Татарстан Республикасының Атказанган югары мәктәп хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, фәнни һәм мөгаллимлек эшчәнлегендәге казанышлары, югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт автономияле мәгариф учреждениесенең Икътисад һәм финанс институты икътисад теориясе кафедрасы доценты | Сафиуллина Кафия Гайфулла кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган югары мәктәп хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 24 декабрь
№ ПУ-1115

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2038. «Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте, авыл хуҗалыгы производствосын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Әтнә муниципаль районының «Күлле Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы | Хәкимуллин Марат Солтан улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 24 декабрь
№ ПУ-1116

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2039. «Татарстан Республикасының Атказанган газ тармагы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасы газ сәнәгатен үстерүгә зур өлеш керүе өчен

| | |
|---|---|
| «Газпром» ачык акционер җәмгыятенең «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте «Чаллыгаз» эксплуатация-производство идарәсе башлыгы | Галиев Мөнәвир Инсаф улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган газ тармагы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 25 декабрь
№ ПУ-1117

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2040. «Татарстан Республикасының Атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

Дәүләт учреждениесе – Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры драма артисты — Гарифуллин Нариман Габдрахман улына

«Татарстан Республикасының Атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 25 декабрь
№ ПУ-1118

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2041. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм төзелеш өлкәсендәге зур казанышлары өчен

«Татар махсус фәнни-реставрация идарәсе» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры, Казан шәһәре — Егорушкин Юрий Анатольевичка

«Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 26 декабрь
№ ПУ-1119

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2042. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте, нефть һәм газ эшкәртү өлкәсен, химия фәнен һәм нефтьне, газны, нефть продуктларын күкертле кушылмалардан чистарту процесслары технологиясен үстерүгә, югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе, актив фәнни-оештыру һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен

| | |
|---|---|
| «Идел углеводород чималы фәнни-тикшеренү институты» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты, техник фәннәр докторы | Мазһаров Әхмәт Мазһар улын |

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 26 декабрь
№ ПУ-1120

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2043. «Татарстан Республикасының Атказанган химигы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм Татарстан Республикасының химия сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Л.Я. Карпов исемендәге химия заводы» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры, Менделеевск шәһәре | Шәмсин Дамир Рафис улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган химигы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 28 декабрь
№ ПУ-1121

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2044. «Татарстан Республикасының Атказанган машина төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте, илебездә машина төзү тармагын үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «РариТЭК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры, Тукай муниципаль районы | Батыршин Рафаэль Рим улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган машина төзүчесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 28 декабрь
№ ПУ-1122

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2045. Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Азнакай районының Урсай авылы;

Буа районының Янтуган авылы;

Мөслим районының Яңа Усы авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Азнакай шәһәренең Тау асты урамы;

Аксубай районының Аксубай шәһәр тибындагы поселогындагы Муса Җәлил урамы;

Балтач районы Пыжмара авылының Тукай урамындагы 13-33 номерлы шәхси йорт хуҗалыклары;

Түбән Кама шәһәренең Вахитов урамындагы 9 номерлы йорт яны территориясе;

Спас районы Иске Рәҗәп авылындагы «Хәмидуллин Д.М.» крестьян (фермер) хуҗалыгы;

Лениногорск районының Куакбаш авылы янындагы «Маркс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең машина-трактор паркы.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару һәм кыргый җәнлекләрне (аларны зоопаркларга чыгару өчен, башка районнарда үрчетү максатларында) тоту;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудырган хайваннарны ит өчен сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 28 декабрь
№ ПУ-1123

## 2046. Татарстан Республикасының Азнакай районы Сарлы авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының Азнакай районы Сарлы авылы территориясендә;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Саба районының Тимершык авылындагы Ленин урамы;

Азнакай районы Банки-Сукаеш авылы янындагы «Азнакайнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенең СКН 4298 номерлы нефть скважинасы яны территориясе;

Алексеевск районының Зур Тигәнәле авылы янындагы «Алан» фермер хуҗалыгы.

2. Түбәндәгеләрнең үз көчләрен югалтуын танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Азнакай районы Сарлы авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 18 октябрендәге ПУ-878 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 9 октябрендәге ПУ-863 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 28 декабрь
№ ПУ-1124

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2047. «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, мәдәниятне саклау һәм үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Казан» милли мәдәни үзәге» Казан шәһәре муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең Милли мәдәният музее лекторлар төркеме мөдире | Кариева Ляйсян Әнәс кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 28 декабрь
№ ПУ-1125

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2048. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, банк эшен үстерүгә һәм камилләштерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Россия саклык банкы» ачык акционер җәмгыятенең 4698 номерлы Зеленодольск бүлекчәсе идарәчесе урынбасары | Кислова Ирина Александровнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 28 декабрь
№ ПУ-1126

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2049. «Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте, халык сәламәтлеген саклау эшендәге зур казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт сәламәтлек саклау автономияле учреждениесенең 1 номерлы онкология (1 нче торакаль хирургия) бүлекчәсе өлкән шәфкать туташы | Сәхәпова Лена Марс кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 28 декабрь
№ ПУ-1127

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2050. «Татарстан Республикасының Атказанган урманчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасының урманчылык тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы «Саба укыту-тәҗрибә урман хуҗалыгы» дәүләт бюджет учреждениесенең урман мастеры | Кашапов Ринат Габделфәрт улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган урманчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 28 декабрь
№ ПУ-1128

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2051. «Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык иҗади эшчәнлеге, Татарстан Республикасы сынлы сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| рәссам | Хисамов Айдар Нурмөхәммәт улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 28 декабрь
№ ПУ-1129

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2052. «Татарстан Республикасының Атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Таттелеком» ачык акционер җәмгыяте Чистай электр элемтәсе зона узелының Алексеевск район электр элемтәсе узелы станция участогы инженеры | Закиров Ирек Хөсәен улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 28 декабрь
№ ПУ-1130

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 2053. «Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре,Татарстан Республикасы халкы сәламәтлеген саклау эшендәге зур казанышлары өчен:

| | |
|---|---|
| «Табиблык-физкультура диспансеры» дәүләт сәламәтлек саклау автономияле учреждениесе баш табибының медицина часте буенча урынбасары, Чаллы шәһәре | Герасимович Геннадий Николаевичка |
| «2 номерлы шәһәр хастаханәсе» дәүләт сәламәтлек саклау автономияле учреждениесенең анестезиология-реанимация бүлекчәсе мөдире, табиб-анестезиологы-реаниматологы, Чаллы шәһәре | Хаҗиев Наил Мөхәмәт улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 28 декабрь
№ ПУ-1131

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2054. «Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| «Чүпрәле үзәк район хастаханәсе» дәүләт автономияле сәламәтлек саклау учреждениесенең Иске Кәкерле фельдшерлык-акушерлык пункты мөдире | Губаева София Зякярья кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 28 декабрь
№ ПУ-1132

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2055. «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, мәдәниятне саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Арча район Мәдәният йорты» муниципаль учреждениесенең Чөмә-Елга авыл клубы мөдире | Әхмәдиева Халидә Мөхәммәтнур кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 28 декабрь
№ ПУ-1133

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2056. «Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, Татарстан Республикасы халкы сәламәтлеген саклау эшендәге зур казанышлары өчен:

| | |
|---|---|
| «Сосновый Бор» шифаханәсе» ачык акционер җәмгыятенең физиотерапия бүлекчәсе мөдире, Зеленодольск муниципаль районы | Хәйруллина Наилә Равил кызына |
| «Татнефть» ачык акционер җәмгыяте һәм Әлмәт шәһәренең медицина-санитария часте» дәвалау-профилактика учреждениесе рентген бүлекчәсе табиб-рентгенологы | Яминов Илшат Харис улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 28 декабрь
№ ПУ-1134

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2057. «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, театр сәнгате өлкәсендә югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Казан театр училищесы» урта һөнәри белем бирү дәүләт автономияле мәгариф учреждениесенең сәхнә сөйләме укытучысы | Пичугина Фәридә Мансур кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 28 декабрь
№ ПУ-1135

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2058. Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында Россия Федерациясе гражданнарын хәрби исәпкә кую комиссияләре составларын раслау турында

Татарстан Республикасында яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын хәрби исәпкә куюны оештыру максатларында, шулай ук аерым затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законның 9 статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында Россия Федерациясе гражданнарын хәрби исәпкә кую комиссияләре составларын һәм резерв составларын (оригиналга 1 нче һәм 2 нче кушымталар) расларга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында Россия Федерациясе гражданнарын хәрби исәпкә кую комиссияләре составларын раслау турында» 2011 елның 30 декабрендәге ПУ-894 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ 2013 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 28 декабрь
№ ПУ-1136

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 2059. Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнарының һәм шәһәр округлары, муниципаль районнар җирле үзидарә органнарының эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү мәсьәләләре буенча хокукый җайга салу үзгәрү белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Шәһәр округлары һәм муниципаль районнар җирле үзидарә органнарының эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2008 елның 28 апрелендәге 607 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указын «Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2008 елның 26 маендагы ПУ-246 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 26 мартындагы ПУ-177 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәреш белән), 3 пунктның бишенче абзацын төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының хисап елында эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен ирешелгән күрсәткечләр дәрәҗәсе һәм өчеллык чорга аларның планлаштырылучы дәрәҗәләре турында Татарстан Республикасы Президенты докладын һәм Татарстан Республикасы шәһәр округларының һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген мониторинглау йомгаклары хакында Татарстан Республикасы җыелма докладын әзерләү тәртибе турында» 2009 елның 26 мартындагы ПУ-177 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «ирешелгәннәр турында» сүзләрен «фактта ирешелгәннәр турында» сүзләренә алмаштырырга;

б) преамбулада:

«ирешелгәннәр турында» сүзләрен «фактта ирешелгәннәр турында» сүзләренә алмаштырырга;

«Россия Федерациясе Президентының 2007 елның 28 июнендәге 825 номерлы Указы» сүзләрен «Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 21 августындагы 1199 номерлы Указы» сүзләренә алмаштырырга;

в) 1 пунктның икенче абзацында «ирешелгәннәр турында» сүзләрен «фактта ирешелгәннәр турында» сүзләренә алмаштырырга;

г) 1 номерлы кушымтада:

атамасында «ирешелгәннәр турында» сүзләрен «фактта ирешелгәннәр турында» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «ирешелгәннәр турында» сүзләрен «фактта ирешелгәннәр турында» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктның өченче абзацында «Россия Федерациясе Президентының 2007 елның 28 июнендәге 825 номерлы Указы» сүзләрен «Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 21 августындагы 1199 номерлы Указы» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «20 мартка кадәр» сүзләрен «10 мартка кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта «10 апрельгә кадәр» сүзләрен «20 мартка кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта «20 апрельгә кадәр» сүзләрен «25 мартка кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

д) 2 номерлы кушымтаның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

Җыелма доклад проектын әзерләү координаторын (алга таба – Координатор) билгели;

катнашучыларны муниципаль берәмлекләр башлыклары докладларын формалаштыру өчен мәгълүмат әзерләү буенча методик материаллар белән тәэмин итә;

Җыелма доклад проектын карый, Җыелма докладны Татарстан Республикасы Президентына тапшыра һәм аны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итә.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә.

4. Әлеге Указ, әлеге Указга кул куйган көннән үз көченә керүче 3 пункттан гайре, 2013 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 29 декабрь
№ ПУ-1137

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 2060. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы структурасы турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының кушымтада бирелүче структурасын расларга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2008 елның 17 маендагы ПУ-228 номерлы Указының 2 пункты үз көчен югалтуын таныарга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә һәм аны гамәлгә ашыру буенча башка карарлар кабул итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 29 декабрь
№ ПУ-1138

Татарстан Республикасы
Президентының
2012 елның «29» декабрендәге
ПУ1138 номерлы Указы белән
расланды

## Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы структурасы



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 2061. Татарстан Республикасы Президентының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында

Кайбер затларның башка эшкә күчүләре һәм вазыйфаларының атамалары үзгәрү белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында террорга каршы көрәшү комиссиясе эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре турында» 2006 елның 4 апрелендәге ПУ-128 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 18 августындагы ПУ-314 номерлы, 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-645 номерлы, 2008 елның 5 сентябрендәге ПУ-443 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-205 номерлы, 2009 елның 22 июнендәге ПУ-342 номерлы, 2010 елның 22 мартындагы ПУ-157 номерлы, 2010 елның 3 июнендәге ПУ-362 номерлы, 2011 елның 1 июнендәге ПУ-299 номерлы, 2011 елның 15 августындагы ПУ-504 номерлы, 2012 елның 14 мартындагы ПУ-203 номерлы һәм 2012 елның 23 июнендәге ПУ-496 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында террорга каршы көрәшү комиссиясенең (алга таба – Комиссия) персональ составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан М.И. Гатинны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Моратов Марат Яшәр улын – Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасарын;

б) Комиссия әгъзасы Р.М. Ильясовның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе – Татарстан Республикасының баш суд приставы».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында хокук тәртибен тәэмин итү буенча Координация киңәшмәсе турында» 2010 елның 25 декабрендәге ПУ-864 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 20 гыйнварындагы ПУ-18 номерлы, 2011 елның 23 мартындагы ПУ-147 номерлы, 2011 елның 15 августындагы ПУ-504 номерлы, 2012 елның 24 гыйнварындагы ПУ-42 номерлы һәм 2012 елның 23 июнендәге ПУ-496 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында хокук тәртибен тәэмин итү буенча Координация киңәшмәсе составына, Татарстан Рес-

публикасында хокук тәртибен тәэмин итү буенча Координация киңәшмәсе әгъзаларының вазыйфаларын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

Р.М. Ильясовның – «Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе – Татарстан Республикасының баш суд приставы»;

П.М. Николаевның – «Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе җитәкчесе».

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре турында» 2000 елның 6 июнендәге ПУ-394 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2000 елның 6 июлендәге ПУ-491 номерлы, 2000 елның 2 ноябрендәге ПУ-829 номерлы, 2002 елның 31 гыйнварындагы ПУ-65 номерлы, 2002 елның 15 ноябрендәге ПУ-992 номерлы, 2003 елның 1 апрелендәге ПУ-235 номерлы, 2003 елның 4 августындагы ПУ-563 номерлы, 2004 елның 10 мартындагы ПУ-163 номерлы, 2004 елның 21 июнендәге ПУ-461 номерлы, 2004 елның 14 сентябрендәге ПУ-604 номерлы, 2005 елның 28 маендагы ПУ-214 номерлы, 2005 елның 22 декабрендәге ПУ-513 номерлы, 2006 елның 18 февралендәге ПУ-64 номерлы, 2006 елның 4 апрелендәге ПУ-128 номерлы, 2006 елның 18 маендагы ПУ-179 номерлы, 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-646 номерлы, 2007 елның 25 декабрендәге ПУ-698 номерлы, 2008 елның 17 декабрендәге ПУ-660 номерлы, 2009 елның 3 июнендәге ПУ-318 номерлы, 2010 елның 4 февралендәге ПУ-42 номерлы, 2010 елның 21 июлендәге ПУ-475 номерлы, 2010 елның 9 декабрендәге ПУ-798 номерлы, 2012 елның 23 июнендәге ПУ-496 номерлы һәм 2012 елның 27 сентябрендәге ПУ-786 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының Мәгълүмати куркынычсызлык буенча ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Б.И. Исмәгыйлевне, А.Р. Хәйруллинны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Посохов Владимир Витальевичны – Татарстан Республикасы прокурорының оператив исәп-хисап һәм статистика буенча өлкән ярдәмчесе (килешү буенча);

Ткаченко Антон Андреевичны – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының мәгълүмати технологияләр, элемтә һәм мәгълүматны саклау бүлеге башлыгы.

4. Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 2 мартындагы 120 номерлы боерыгы белән расланган 2012-2014 елларга Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремизмны кисәтү буенча республика максатчан программасын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме (алга таба – эш төркеме) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) эш төркеме составыннан И.Х. Әюпованы, М.И. Гатинны, А.К. Зиннуровны, В.Г. Карузинны, А.С. Кондратьевны, А.М. Терентьевны чыгарырга;

б) эш төркеме составына кертергә:

Гарифуллин Рөстәм Марат улын – Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры урынбасарын;

Кадыйров Рөстәм Раиф улын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе башлыгын;

Минкина Гүзәлия Тәлгать кызын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасарын;

Нигъмәтуллина Гүзәл Азат кызын – Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасарын;

Селивановский Алексей Владимировичны – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасарын.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 29 декабрь
№ ПУ-1139

## 2062. Татарстан Республикасының Чирмешән районы Сосновка авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының 3[1], 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә:

а) Татарстан Республикасының Чирмешән районы Сосновка авылы территориясендә;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Азнакай районының Мәсгут авылындагы Дуслык урамы;

Азнакай районының Митрәй авылындагы Тау асты урамы;

Аксубай районының Иске Узи авылындагы Яшьләр урамы;

Әтнә районының Ташчишмә авылындагы Шамил Усманов урамы;

Баулы районының Яңа Зареченский поселогындагы Вахитов урамы;

Кукмара районының Зур Кукмара авылындагы Елга аръягы урамы;

Лаеш районының Лаеш шәһәрендәге Есенин урамы.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару һәм кыргый җәнлекләрне (аларны зоопаркларга чыгару өчен, башка районнарда үрчетү максатларында) тоту;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудырган хайваннарны ит өчен сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 29 декабрь
№ ПУ-1140

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2063. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм предприятиенең эчке мәгълүмати мохитен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Алабуга автомобиль заводы производство берләшмәсе» ачык акционер җәмгыяте баш белгече – кадрлар департаментын мәгълүмати тәэмин итү төркеме җитәкчесе | Зарипова Нурия Хаммат кызын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 29 декабрь
№ ПУ-1141

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2064. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләү турында

Күпьеллык иҗади эшчәнлеге, татар театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Дәүләт учреждениесе – Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры драма артисты | Миңнуллина Нәҗибә Гыймай кызын |

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 29 декабрь
№ ПУ-1142

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2065. «Татарстан Республикасының Атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирү турында

Музыка сәнгатен пропагандалауга шәхси өлеш кертүләре өчен Беренче каналда «Голос» музыкаль телевизион проектында җиңүчеләр:

| | |
|---|---|
| җырчы | Гарипова Динә Фәһим кызына |
| җырчы | Кәлимуллина Эльмира Рамил кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 30 декабрь
№ ПУ-1143

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2066. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклаудагы казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Лаеш район суды рәисе | Фазлыев Фирдәвес Хәнип улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 30 декабрь
№ ПУ-1144

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 2067. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору советы составына үзгәрешләр кертү турында

Кайбер затларның башка эшкә күчүләре белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору советы турында» 2011 елның 21 февралендәге ПУ-71 номерлы Указы белән (2011 елның 15 августындагы ПУ-504 номерлы һәм 2012 елның 24 июлендәге ПУ-617 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан А.Х. Гыйльметдиновны, В.Г. Карузинны, М.Я. Моратовны чыгарырга;

б) Совет составына кертергә:

Кадыйров Рөстәм Раиф улын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе башлыгын;

Миңнәхмәтов Ирек Җәүдәт улын – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесен;

Фәттахов Энгель Нәвап улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 30 декабрь
№ ПУ-1145

## 2068. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

### Татарстан Республикасында олимпия уты эстафетасын оештыру һәм уздыру буенча ведомствоара эш төркеме төзү турында

Татарстан Республикасы һәм «2014 елда Сочи шәһәрендә XXII Кышкы олимпия уеннарын һәм XI Кышкы паралимпия уеннарын оештыру комитеты» автономияле коммерциячел булмаган оешмасы арасында хезмәттәшлек турында 2011 елның 31 маендагы GR/11/05/31-1 номерлы килешүгә Татарстан Республикасы территориясендә олимпия уты эстафетасын оештыру һәм уздыру турында 2012 елның 15 мартындагы 1 номерлы Өстәмә килешүнең 2.4 пунктын гамәлгә ашыру максатларында:

1. «2014 елда Сочи шәһәрендә XXII Кышкы олимпия уеннарын һәм XI Кышкы паралимпия уеннарын оештыру комитеты» автономияле коммерциячел булмаган оешмасы белән үзара хезмәттәшлек итү өчен җаваплы зат итеп Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе Ш.Х. Гафаровны билгеләп куярга.

2. Татарстан Республикасында олимпия уты эстафетасын оештыру һәм уздыру буенча ведомствоара эш төркеме төзергә һәм аның составын (кушымтада бирелә) расларга.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 04 декабрь
№ 534

Татарстан Республикасы
Президентының
2012 елның «04» декабрендәге
534 номерлы боерыгы белән
расланды

## Татарстан Республикасында олимпия уты эстафетасын оештыру һәм уздыру буенча ведомствоара эш төркеме составы

| | |
|---|---|
| Гафаров Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, эш төркеме рәисе |
| Борһанов Рафис Тимерхан улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры, эш төркеме рәисе урынбасары |
| Калинкин Денис Геннадьевич | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты аппараты җитәкчесе, эш төркеме рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары |
| Батин Сергей Леонидович | «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Гыйльманов Рафаил Вәли улы | Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры урынбасары – полиция башлыгы (килешү буенча) |
| Кондратьев Андрей Станиславович | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт тормыш рәвешен формалаштыру мәсьәләләре бүлеге башлыгы |
| Миңнәхмәтов Ирек Җәүдәт улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Негин Егор Владимирович | «2014 елда Сочи шәһәрендә XXII Кышкы олимпия уеннарын һәм XI Кышкы паралимпия уеннарын оештыру комитеты» автономияле коммерциячел булмаган оешма проектлары җитәкчесе (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин Эмил Фидаил улы | «2013 елда Казан шәһәрендә XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиадасы Башкарма дирекциясе» автономияле коммерциячел булмаган оешмасының ут эстафетасы бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Осипов Сергей Альбертович | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Пантелеева<br>Ольга Викторовна | «2014 елда Сочи шәһәрендә XXII Кышкы олимпия уеннарын һәм XI Кышкы паралимпия уеннарын оештыру комитеты» автономияле коммерциячел булмаган оешмасының Россия буенча Олимпия уты эстафетасы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Поминов<br>Андрей Иванович | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары |
| Сивов<br>Игорь<br>Вениаминович | «2013 елда Казан шәһәрендә XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиадасы Башкарма дирекциясе» автономияле коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Фәйзрахманов<br>Марат Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры |

## 2069. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм предприятиенең финанс-икътисадый эшчәнлеген оештыруга шәхси өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Татспиртпром» ачык акционер җәмгыяте финанс директоры | Каюмова Әлфия Садрислам кызына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 05 декабрь
№ 537

## 2070. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм Татарстан Республикасының төзелеш комплексын үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Татэлектромонтаж» ачык акционер җәмгыятенең Түбән Кама монтаж идарәсе энергия тапшыру челтәрләре һәм электр җайланмалары электромонтажчысы | Фәсәхетдинов Иршат Хәсәнҗан улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 06 декабрь
№ 539

## 2071. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыруга лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгының балалар һәм яшьләр оешмалары белән эшләү бүлеге әйдәүче киңәшчесе | Копылова Ирина Александровнага |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 06 декабрь
№ 540

## 2072. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм Татарстан Республикасында төзелеш комплексын үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Эстель» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры | Нуриев Илһам Данир улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 06 декабрь
№ 541

## 2073. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Татарстан Республикасының юл тармагында кадрлар сәясәтен тормышка ашырудагы күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Татавтодор» ачык акционер җәмгыяте кадрлар бүлеге башлыгы | Мергасова Татьяна Станиславовнага |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 06 декабрь
№ 542

## 2074. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм Татарстан Республикасында агросәнәгать комплексын үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Актаныш муниципаль районы «Чишмә» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең товарлыклы-сөтчелек фермасы мөдире | Әхмәтов Ринат Сәнәф улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 06 декабрь
№ 543

## 2075. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, законлылыкны, хокук тәртибен, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен яклауны тәэмин итүгә шәхси өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы | Баһаутдинов Флер Нуретдин улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 06 декабрь
№ 544

## 2076. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Җирле үзидарә органнарында нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты эшләр идарәчесе | Мөгыйнов Хәким Сәгыйть улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 06 декабрь
№ 545

## 2077. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Шабанов Тәлгать Әнвәр улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы, Спас муниципаль районы | Шабанов Тәлгать Әнвәр улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 06 декабрь
№ 546

## 2078. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм финанс-икътисад эшчәнлеге өлкәсендәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Профсоюзларның дәвалау-профилактика учреждениесе «Бәкер» шифаханәсе баш бухгалтеры | Фәсхетдинова Галия Минәхмәт кызына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 06 декабрь
№ 547

## 2079. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Нәтиҗәле хезмәте һәм Татарстан Республикасының төзелеш комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры | Фәйзуллин Ирек Әнвәр улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 07 декабрь
№ 548

## 2080. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Татарстан Республикасында медицина-социаль экспертиза хезмәтен үстерүгә, реабилитация-эксперт диагностикасы сыйфатын яхшыртуга һәм Татарстан Республикасы халкының аннан файдалануын арттыруга лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Баш медицина-социаль экспертиза бюросы» федераль казна учреждениесе җитәкчесе | Низамов Ригель Хәләф улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 07 декабрь
№ 549

## 2081. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

### Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары кандидатураларын алдан карау буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия составына үзгәрешләр кертү турында

Аерым затларның башка эшкә күчүе һәм вазыйфалары атамаларының үзгәрүе белән бәйле рәвештә:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары кандидатураларын алдан карау һәм раслау тәртибе турында» 2005 елның 8 ноябрендәге 320 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 19 ноябрендәге 305 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге 97 номерлы һәм 2011 елның 13 апрелендәге 171 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары кандидатураларын алдан карау буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан А.Х. Гыйльметдиновны чыгарырга;

б) Комиссия составына Мостафин Данил Мәхмүт улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасарын кертергә;

в) Комиссия әгъзаларының вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Терентьев Александр Михайлович – «Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе»;

Әюпова Ирада Хафизҗан кызы – «Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары».

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 07 декабрь
№ 550

## 2082. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Нәтиҗәле хезмәтләре һәм Татарстан Республикасының салым хезмәтен үстерүгә өлеш кертүләре өчен:

| | |
|---|---|
| Федераль салым хезмәтенең 3 нче районара инспекциясе башлыгы | Галиуллина Зөлфия Илдар кызына |
| Федераль салым хезмәте Татарстан Республикасы буенча идарәсенең бурычка керүләрне җайга салу һәм банкротлык процедураларын тәэмин итү бүлеге башлыгы | Ибәтуллина Илсөяр Нурмөхәммәт кызына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 12 декабрь
№ 551

## 2083. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Татарстан Республикасы территориясендә федераль бюджетны үтәү буенча нәтиҗәле эше өчен Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе коллективын Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләргә
(тексты кушымтада бирелә).

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 12 декабрь
№ 552

## 2084. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү өлкәсендәге нәтиҗәле хезмәтләре өчен:

| | |
|---|---|
| «Спорткультавтотовары» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры | Гафиятуллин Мөнир Минхәйдәр улына |
| «Мигра» юридик агентлыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры | Закиров Роберт Камил улына |
| «Ваш Быт» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры | Сафин Фәрит Рәшит улына |
| «Контр» икътисадый куркынычсызлык агентлыгы» сак предприятиесе ябык акционер җәмгыяте генераль директоры | Янышев Илдус Әхтәм улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 12 декабрь
№ 553

## 2085. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Нәтиҗәле хезмәте һәм «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Свияжск утрау-шәһәре» проектын гамәлгә ашыруга лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Грань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте җитештерү буенча директор хезмәтенең проектлар менеджерлары төркеменең проект менеджеры | Әхмәтов Эдуард Иран улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 12 декабрь
№ 554

## 2086. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Кече һәм урта бизнес предприятиеләре ассоциациясен Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләргә

(тексты кушымтада бирелә).

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 12 декабрь
№ 555

## 2087. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Нәтиҗәле хезмәтләре, финанс-икътисад эшчәнлеге өлкәсендәге казанышлары өчен Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре:

| | |
|---|---|
| юридик бүлек башлыгы | Акчурина Тамилла Гыйльман кызына |
| Идарә җитәкчесе урынбасары | Гыйлаҗев Рөстәм Ринат улына |
| федераль реестрлар алып бару бүлеге башлыгы | Габҗәлилова Рәсимә Мирсәлим кызына |
| финанс тәэминаты, бюджет исәбе һәм бюджет операцияләре буенча хисап бүлеге өлкән казначысы | Ильина Резеда Рәгыйп кызына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 12 декабрь
№ 556

## 2088. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык намуслы хезмәтләре, финанс-икътисад эшчәнлеге өлкәсендәге казанышлары өчен:

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе | Дубкова Ирина Владимировнага |
| Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе | Козина Светлана Анатольевнага |
| Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Финанс-бюджет һәм җир-милек палатасы рәисе | Кондратьева Ландыш Илдус кызына |
| Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Финанс-бюджет палатасы рәисе | Мөталимова Галия Равил кызына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 12 декабрь
№ 557

## 2089. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык намуслы хезмәтләре һәм Татарстан Республикасында азык-төлек продукциясе җитештерү технологиясен үстерүгә шәхси өлеш кертүләре өчен «ЧАЛЛЫ ИКМӘГЕ» ябык акционер җәмгыяте хезмәткәрләре:

| | |
|---|---|
| икмәк пешерүче | Галиева Таһира Хабий кызына |

производство мичләре кочегары — Гыйззәтуллина Рушания Мәгъсум кызына

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 13 декабрь
№ 558

## 2090. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Нәтиҗәле хезмәте һәм гражданлык җәмгыяте институтларын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының сәламәтлек саклау һәм сәламәт яшәү рәвеше мәсьәләләре буенча эш төркеме җитәкчесе — Менделевич Владимир Давыдовичка

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 13 декабрь
№ 559

## 2091. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Татарстан Республикасының дәүләти, икътисадый һәм сәяси үсешенә, граждан җәмгыяте институтларын формалаштыруга зур өлеш кертүе өчен

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе — Хәйруллин Илгиз Кәлимулла улына

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 13 декабрь
№ 560

## 2092. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Татарстан Республикасында спортның техник төрләрен үстерүгә зур өлеш кертүләре өчен:

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасының Автомобиль һәм мотоциклет спорты федерациясе» төбәк җәмәгать оешмасы президиумы әгъзасы | Дадаев Аркадий Николаевичка |
| «Татарстан Республикасының Автомобиль һәм мотоциклет спорты федерациясе» төбәк җәмәгать оешмасының картинг комитеты рәисе урынбасары, «Картинг үзәге» автономияле коммерциячел булмаган оешма директоры | Кузьмин Владимир Ивановичка |
| «Татарстан Республикасының Автомобиль һәм мотоциклет спорты федерациясе» төбәк җәмәгать оешмасының техник директоры | Мортазина Резеда Әнәс кызына |
| «Татарстан Республикасының Автомобиль һәм мотоциклет спорты федерациясе» төбәк җәмәгать оешмасы баш белгече | Сафиуллина Гөлназ Гаяз кызына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 14 декабрь
№ 565

## 2093. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Эчке эшләр органнарында күп еллар намуслы хезмәт итүе, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга шәхси өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры урынбасары – баш тикшерү идарәсе башлыгы, юстиция полковнигы | Селивановский Алексей Владимировичка |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 14 декабрь
№ 566

## 2094. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык педагогик һәм тәрбия эшчәнлеге, медицина өлкәсенә кадрлар әзерләүгә зур өлеш кертүе өчен «Казан медицина көллияте» урта һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе коллективын Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләргә

(тексты кушымтада бирелә).

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 14 декабрь
№ 567

## 2095. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Нәтиҗәле хезмәте һәм Татарстан Республикасының транспорт комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсе торак-коммуналь хуҗалыгы һәм транспорт бүлеге баш киңәшчесе | Сафина Лилия Рәфкать кызына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 18 декабрь
№ 569

## 2096. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Җирле үзидарә органнарында нәтиҗәле эше, республиканың социаль-икътисадый, мәдәни үсешенә өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы башлыгы | Батин Сергей Леонидовичка |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 20 декабрь
№ 570

## 2097. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм музей эшен үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениесе директорының беренче урынбасары | Костенников Александр Аркадьевичка |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 21 декабрь
№ 573

## 2098. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүгә өлеш кертүләре өчен:

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Иске Күклек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы | Бахметов Аркадий Борисовичка |
| Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Урта Курса авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы | Вафина Рәмзия Рамазан кызына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 21 декабрь
№ 574

## 2099. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм Татарстан Республикасының мәгълүмати статистик ресурс формалаштыруга дәүләт йөкләмәләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү эшенә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитеты рәисе урынбасары | Семенова Ольга Юрьевнага |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 21 декабрь
№ 575

## 2100. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм Татарстан Республикасының суд системасын үстерүгә, судлар эшчәнлеген тәэмин итүгә лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Суд департаментының Татарстан Республикасында идарәсе башлыгы | Сәлахов Җәүдәт Җәләлетдин улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 21 декабрь
№ 576

## 2101. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм республика нефть сәнәгатен үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| нефть сәнәгате ветераны | Лобанов Борис Степановичка |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 21 декабрь
№ 577

## 2102. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм Татарстан Республикасы төзелеш комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Камгэсэнергострой» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры | Евдокимов Александр Сергеевичка |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 22 декабрь
№ 578

## 2103. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Намуслы хезмәтләре, авария, һәлакәт һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен кисәтү һәм бетерүгә шәхси өлеш кертүләре өчен:

| | |
|---|---|
| «Федераль янгынга каршы хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча 15 нче отряды» федераль дәүләт казна учреждениесенең 89 номерлы янгын часте каравыл башлыгы ярдәмчесе, эчке хезмәт өлкән прапорщигы | Вилданов Илгиз Хәсәнгата улына |
| «Федераль янгынга каршы хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча дәүләт янгынга каршы хезмәте 1 нче отряды (шартнамә буенча)» федераль казна учреждениесе башлыгы | Шаповалов Алексей Алексеевичка |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 24 декабрь
№ 579

## 2104. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Казан шәһәре буенча территориаль бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | Фәхертдинов Шәриф Гыйльфан улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 24 декабрь
№ 580

## 2105. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык иҗади эшчәнлеге һәм татар театры сәнгатен үстерүгә лаеклы өлеше өчен

| | |
|---|---|
| хезмәт ветераны | Ганиева Рауза Котдус кызына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 24 декабрь
№ 581

## 2106. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык иҗади эшчәнлеге һәм татар театр сәнгатен үстерүгә лаеклы өлеше өчен

| | |
|---|---|
| дәүләт учреждениесе – Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры драма артисты | Таҗетдинов Ринат Арифҗан улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 24 декабрь
№ 582

## 2107. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм Татарстан Республикасында Россия федераль таможня хезмәте инфраструктурасын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| хезмәт ветераны | Вәлитов Наил Мәхмүт улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 24 декабрь
№ 584

## 2108. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм торак-коммуналь хуҗалыгы тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Тукай муниципаль районының «Тукайтеплогаз» муниципаль унитар предприятиесе директоры | Насыйбуллин Вахит Шәриф улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 27 декабрь
№ 585

## 2109. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Намуслы хезмәтләре, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга шәхси өлеш кертүләре өчен:

| | |
|---|---|
| Казан шәһәренең Идел буе районы прокуроры урынбасары | Муллануров Ленар Шәрхынур улына |
| Татарстан Республикасы прокуратурасының коррупциягә каршы көрәшү турында законнарны үтәүгә күзәтчелек бүлеге өлкән прокуроры | Шакирҗанов Руслан Ринат улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 27 декабрь
№ 587